МИНИСТЕРСТВО ОБРАЗОВАНИЯ И НАУКИ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МӘГАРИФ ҺӘМ ФӘН МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

09.12.2019 Казан шәһәре № под-1809/19

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүгә вәкаләтле вазыйфаи затлары исемлеген раслау турында

Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 28.3 статьясындагы 2, 3 һәм 4 өлешләре нигезендә боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 5.57 статьясында, 9.13 статьясында, 14.1 статьясының 2, 3 һәм 4 өлешләрендә, 18.19 статьясының 2 өлешендә, 19.4 статьясының 1 өлешендә, 19.4.1 статьясында, 19.5 статьясының 1 өлешендә, 19.6, 19.7, 19.20, 19.30 статьяларында каралган административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүгә вәкаләтле вазыйфаи затларының кушымтада бирелгән исемлеген расларга.
2. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының «Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүгә вәкаләтле вазыйфаи затлары исемлеген раслау турында» 2012 елның 22 октябрендәге 5571/12 номерлы боерыгын гамәлдән чыккан дип танырга.
3. Әлеге боерык үтәлешен контрольдә тотуны министр урынбасары – Мәгариф өлкәсендә күзәтчелек һәм контрольлек департаменты җитәкчесе Н.В. Гречанниковка йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер министры урынбасары – министр Р.Т.Борһанов

Татарстан Республикасы
Мәгариф һәм фән
министрлыгының
09.12.2019 № под-1809/19
боерыгы белән расланды

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 5.57 статьясында, 9.13 статьясында, 14.1 статьясының 2, 3 һәм 4 өлешләрендә, 18.19 статьясының 2 өлешендә, 19.4 статьясының 1 өлешендә, 19.4.1 статьясында, 19.5 статьясының 1 өлешендә, 19.6, 19.7, 19.20, 19.30 статьяларында каралган административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүгә вәкаләтле вазыйфаи затлары исемлеге

1. Министр урынбасары – Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының Мәгариф өлкәсендә күзәтчелек һәм контрольлек департаменты җитәкчесе.

2. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының Мәгариф өлкәсендә күзәтчелек һәм контрольлек департаменты җитәкчесе урынбасары.

3. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының Мәгариф өлкәсендә күзәтчелек һәм контрольлек департаментының түбәндәге бүлекләре җитәкчеләре:

- мәгариф өлкәсендә дәүләт күзәтчелеге;
- белем бирү сыйфатын дәүләт контролендә тоту;
- белем бирү эшчәнлегенә дәүләт аккредитациясе;
- белем бирү эшчәнлеген лицензияләү;
- белем бирү оешмаларын лицензия контролендә тоту;
- хокукый җайга салу;
- белем алу һәм (яки) квалификация турында документларны раслау;
- аналитика, мәгълүмат һәм оештыру ягыннан тәэмин итү.

4. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының Мәгариф өлкәсендә күзәтчелек һәм контрольлек департаментындагы түбәндәге бүлекләрнең әйдәп баручы киңәшчеләре, әйдәп баручы консультантлары, әйдәп баручы белгечләре:

- мәгариф өлкәсендә дәүләт күзәтчелеге;
- белем бирү сыйфатын дәүләт контролендә тоту;
- белем бирү эшчәнлегенә дәүләт аккредитациясе;
- белем бирү эшчәнлеген лицензияләү;
- белем бирү оешмаларын лицензия контролендә тоту;
- хокукый җайга салу;
- белем алу һәм (яки) квалификация турында документларны раслау;
- аналитика, мәгълүмат һәм оештыру ягыннан тәэмин итү.